# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№1** **24.11.2024 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге составына керүче Каменка авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Уставы нигезендә 2024 елның 24 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Сез 2025 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Каменка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 3500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау, тоту (Җәлил урамына вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Каменка торак пункты территориясен төзекләндерү (тракторчыга механикалаштырылган кар чистарту буенча хезмәтләр өчен түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 14 гражданнар теркәлгән, гражданнар җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 9.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 9, «КАРШЫ» » позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Каменка торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. Түбәнәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

«Сез 2025 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Каменка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 3500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау, тоту (Җәлил урамына вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

-Каменка торак пункты территориясен төзекләндерү (тракторчыга механикалаштырылган кар чистарту буенча хезмәтләр өчен түләү).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагыш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Мәлбагыш авыл җирлеге башлыгы А.Й.Әхмәтшин